**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛАНЫСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Саралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар Сараланы
авылы, Татарстан урамы, 17 нче йорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**2021елның «5 » апреле** **39 номер**

# К А Р А Р

**2020 елда Татар Сараланы авыл җирлеге**
**бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча**
**гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Татар Сараланы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татар Сараланы авыл җирлеге Советының карарлары проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен Татар Сараланы авыл җирлегенең 19 Уставы нигезендә Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карар итте:

2020 елга Татар Сараланы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлауларын 2021 елның 19 апреленә 14.00 сәгатьтә Татар Сараланы авылы мәдәният йорты бинасында билгеләп үтәргә.

2. 2020 елда Татар Сараланы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы хисап буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Татар Сараланы авылы, Татарстан урамы, 17 йорт яисә факс буенча- 4-77-49, 2021 елның 19 апрелеленә кадәр.

3. Җирлекнең башкарма комитетына 2020 елда Татар Сараланы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча гражданнарның гавами тыңлауларын үткәрүне, тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

4. 2020 елда Татар Сараланы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисап буенча әлеге карар белән Татарстан урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында танышырга була.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Татар Сараланы авыл җирлеге**
**Советы рәисе:** **Мөбәрәкшин И.Ф.**